# ***Бөек Ватан сугышында катнашкан укытучыларыбыз***

Альбомны эшләде: рус теле һәм әдәбияты укытучысы
Рахимова Фәния Данис кызы



1941 нче елның 21 июне һәм 1945 елның 25 мае. Шушы ике көн арасында Ватаныбызның тарихының аерым бер олы сәхифәсе ята. Ул –совет халкының Бөек Ватан сугышында фашистлар Германиясенә һәм аның союздашларына каршы 1418 көн һәм төн буена фидакарь көоәше сәхифәсе.

Бу дөнья тарихындагы иң авыр сугыш була. Аның нәтиҗәсендә совет халкы миллионнарча корбаннар исәбенә үз Ватанының иминлеген, бәйсезлеген саклап кала, дөнья өивилизаөиясен коткаруга хәлиткеч өлеш кертә.

Бөек Ватан сугышының җиңү белән тәмамлануы сугышчыларның һәм тыл хезмәтчәннәренең масса –күләм сугышчан һәм хезмәт батырлыгы, фидакарьлеге нәтиҗәсе була.Авыр сынау сынау елларында туган илгә мәхәббәт, басып алучыларга карата кайнар нәфрәт совет җәмгыятен бер йодрыкка туплый,аңа бетмәс-төкәнмәс көч бирә.

Татарстан халкы да җиңүгә зур өлеш кертә. Хәрәкәттәге армия сафында республиканың 700 меңгә якын кешесе илнең азатлыгын яулауда катнаша. Шулар арасында безнең мәктәбебездә эшләгән укытучылар да бар. Барысы 15 укытучыбыз Бөек Ватан сугышында катнашалар, илебезнең азатлыгы өчен көрәштә фидакарь батырлык үрнәкләре күрсәтәләр. Шулар арасыннанҗиде мөгаллим изге көрәштә һәлак булалар. Ә сигезе исән-сау кайтып, сугыштан соң илебезне торгызуда, балаларга белем бирүдә армый-талмый эшлиләр.

# *Бөек ватан сугышында һәлак булган укытучылар*

1. Бакиров Даут
2. Галиев Гаяз Мөхетдин улы
3. Нигъматуллин Мәүлит Нигъмәтулла ул
4. Миннегалиев Габделбәр Минегали улы
5. Хәлим абый
6. Гобәйдуллин Габделхак гобәйдулла ул

# *Бөек Ватан сугышыннан исән-сау кайткан укытучылар*

1. Әүхадиев Фәйзи Диннулла улы
2. Бикбаев Госман Латыйп улы
3. Краснов Александр Фёдорович
4. Мурзин Минҗан Морза улы
5. Салихов Шәфыйк Салих улы
6. Фазылҗанов Яхъя
7. Гыйззатуллин Габделхәй
8. Хәбиров Бәдри

ОНЫТЫРГА ХАКЫБЫЗ ЮК

# Солдат боткасын 17 яшьтән

**“1947 елда Иске Масра авыл Советына кергән (Арча районы) Курса Почмак авылында фронттан кайткан 84 кеше бар иде. Хәзер исә исәннәрдән бер мин калганмын”, – дип башлады сүзен Шафик Салих улы Салихов, сугыш хакында сүз чыккач.**

Бер караганда бу – табигать кануны. Дөньяга килгән адәм баласының дөньядан китүе гайре табигый хәл түгел. Ләкин ... ләкин менә фронтта алган яралар бу китүне бермә-бер диярлек тизләтәләр шул. Ә яу кырыннан кайтучылар арасында яраланмаган кешеләрне бармак белән генә санарлык бит. Шафик ага үзе дә нык яраланган, контузия алган кеше. Шуның нәтиҗәсе буларак колакка катырак.

Яралану афәте нәселдән үк килә кебек. Аның әтисе Салихның да гражданнар сугышында кашы өстенә ядрә тиюдән күзе начарланып кала. Шулай булуга карамастан, Бөек Ватан сугышының шаукымы аңа да тими калмый. Район хәрби комиссариаты 4 балалы гаилә башлыгын Курса разъездында эшкә билгеләтә. Анда ул паровоз өчен утын хәзерләүченең хуҗалык мөдире булып хезмәт итә. Бу вакытта аның өлкән улы Вәли Сталинград өчен барган сугышларда катнаша, штурм авиациясенең очучысы буларак дошман гаскәрләрен бомбага тота. Кызганыч, 1942 елның августында Вәли Салиховның хәбәрсез югалуы турында язу килә. Аның язмышы бүгенге көнгә кадәр ачыкланмаган әле.



1943 елның ноябрь аенда Салих аганың икенче улы Шафикка да район хәрби комиссариатыннан повестка килә. Бу вакытта 17 яше яңа гына “тулып” киткән, чынлыкта аңа 17 яшь 6 декабрьдә генә тула, авыл Советы биргән белешмәдә 30 августта дип язылган була. Шафик Арча педагогика училищесының 3 курсында укый. Хәер, закон нигезендә армиягә 18 яше тулганнарны гына алырга яраганны хәрби комиссариат хезмәткәрләре белмиләрме соң инде? Беләләр һәм Шафикка: “Сине укырга җибәрәбез, укыган вакытта яшең тулачак”, – диләр.

Әнә шулай, кичәге студент Мәскәүгә, аннан соң Лосино-Островский разъезды янындагы хәрби лагерьга эләгә. Күп тә үтми, ул Пушкино шәһәрендә элемтәчеләр курсында укый башлый. Училищеда фән нигезләрен яхшы билгеләренә генә үзләштергән Салиховка элемтәчеләр курсында уку җиңел бирелә. Ярты ел укыгач, иңнәренә сержант погоны таккан Чөмә-Елга авылы егете фронтка озатыла. Өченче Белоруссия фронтына кергән элемтәчеләрнең аерым батальонында отделение командиры итеп билгеләнә ул. Шулай итеп үз кул астына кергән 14 солдат белән элемтәчеләр җилкәсенә төшә торган вазифаларны үти башлый. Штаб элемтәчесе булган офицер һәлак булгач, аның урынына билгеләнә, берара батальон командирының адьютанты булып та хезмәт итә.

Чыбык уралган катушка асып, алгы сызыктагы солдатлар белән элемтә тота-тота отделениесе белән Литвага килеп җитәләр Шафиклар. Даугаупилс, Резекнэ, Шауляй шәһәрләре артта кала. “Ясалма күперләр, саллар, көймәләр белән Неман елгасын кичкәндә бик күп солдатлар һәлак булды. Минем отделение 14 кешедән 6 га гына калды. Шул авырлыкларны җиңә-җиңә Тильзит шәһәрен азат иттек. Кенигсбергка җитәргә 30 чакрымнар кала, бер тимер юл станциясен азат иткәндә нык яраландым, контузия алдым”, – дип искә ала Шафик ага үзенең ничек итеп госпитальгә эләгүе хакында сөйләгәндә.

1945 елның апрелендә Кенигсберг алына. Шуннан соң өченче Белоруссия фронты бетерелә, аннан бушаган частьларны Ерак Көнчыгышка озаталар. Әле терелеп җитмәгән булса да, Шафик Салихов та үз часте белән бергә кузгала. Байкал күле буендагы Слюданка шәһәрендә чакта сугыш беткән хәбәрне ишетәләр алар. Аңлашылганча, сугыш тәмамлангач, иңбашына катушка элгән солдатларга хаҗәт бетә. Салиховлар батальоны да башка хезмәткә – юллар төзүгә тәгаенләнә. Сәламәтлеге какшаган, госпитальгә бер кереп, бер чыгып йөргән Шафикны штабта телефончы итеп утырталар. 1946 елның маенда демобилизациягә үк эләгә ул. Күкрәгенә “Германияне җиңгән өчен” медале таккан Шафик Салиховны өенә офицер озата килә.

Бер яктан туган өй һавасы, икенче яктан яшь организм үзенекен итә 1946 – 1947 уку елында Шафик Салихов янә педагогика училищесында укый башлый. Ә инде август аенда Курса Почмак авылында башлангыч сыйныф балаларын укытырга билгеләнә. Кичәге фронтовик белемен күтәрергә дә онытмый. Казан дәүләт педагогика институтын читтән торып тәмамлый. Югары уку йорты дипломына ия булган егетне башта Иске Масрадагы башлангыч мәктәп мөдире, аннан соң Сикертән җидееллык мәктәбенә тарих укытучысы итеп билгелиләр.

Тырыш егетне районда да күз уңында тоталар. Сикертәндә 5 ел тарих фәненнән белем биргәннән соң, аны яңадан Курса Почмакка, бу юлы андагы сигезъеллык мәктәпкә директор итеп күчерәләр. Бер үк вакытта ул Фрунзе исемендәге колхозның партия оешмасы секретаре вазифаларын да башкара.

Үзе кебек укытучы булып эшләгән авылдашы Фәүзия Шәйхиева белән корган гаиләсе дә төп таянычы була Шафик Салих улының. Директор һәм секретарь буларак иртә таңнан кичке караңгыга кадәр әле мәктәптә, әле колхозчылар арасында йөргәндә Фәүзия гаилә учагын сүндерми генә түгел, балаларына дөрес тәрбия бирүгә дә вакыт таба. Уллары Нияз, кызлары Фирдәүсә һәм Чулпан – барысы да югары белем алалар. Кияүләрдән дә уңдылар алар. Әнә Фирдәүсәнең тормыш иптәше Роберт Имам улы Сәләхов 20 ел инде тимер юл хастаханәсен җитәкли. Татарстанның атказанган табибы, медицина фәннәре кандидаты, мактаулы тимер юлчы исемнәрен йөртә ул. Мәскәүдә яшәүче, “Юкос”ның чит илләр белән элемтә алып баруында күренекле роль уйнаучы Чулпаннары полковник иренә гаилә җылысын бирергә дә өлгерә.

Тугызынчы дистәләрен ваклаучы, уллары Ниязныкын да кертеп 5 оныкка, 2 оныкчыкка ия булган Фәүзия һәм Шафик Салиховлар хәзерге вакытта ел фасылының җәй чорында Курса Почмакта үзләре элек яшәгән төп йортларында, кышын Казанда яшәп гомер кичерәләр.

**Харис ЗАКИРОВ**
**Казан**

# *Салихов Шәфыйкъ Салих улы*



Салихов Шәфыйкъ Салих ул 1926 елның
6 декабрендә Арча районының Чөмә-Елга авылында
туа. 1941 елда Сикертән җидееллык мәктәбен
тәмамлагач, колхозда кырчылык бригадиры булып
эшли.
Шул ук елны Арча педагогия училиәесына укырга
керә.1943 елның ноябрендә Арча хәрби
комиссариаты тарафыннан армиягә чакырыла. Арча
военкоматы Шәфыйкъ абыйны Кукмара военкоматы
карамагына җибәрә.
Кукмара военкоматыннан Мәскәү шәһәренә озатыла
Аннан Мәскәүдән ерак түгел генә Лосино –
Островский разъездыннан урман эченә урнашкан
хәрби частька озаталар. Аннан Мәскәүдән 30 км
ераклыкта урнашкан.





КРАСНОАРМЕЙСКАЯ КНИЖКА



Красноармейскую книжку иметь всегда при себе. Не имеющих книжек—задерживать

1. Фамилия Салихов
2. Имя и отчество Шадик
3. Звание и должность Красноармейц
4. Наименование части (учреждения) 2 отд. бат. т. д. полка связи
5. Наименование подразделения (батальон, рота) 3 б-н 1 рота связи
6. № личного знака

Личная подпись владельца книжки

Место для фотокарточки владельца книжки

Командир роты

1943 г.

(Место печати части)

I. Общие сведения

1. Номер военно-учетной специальности
2. Грамотность и общее образование (если окончил техникум, рабфак или ВУЗ, то указать его название) 9 классов.
3. Национальность татарин
4. Год рождения 1926 года.
5. Год призыва (указать также — нормальный или досрочный призыв)
6. Каким военкоматом призван Арским РВК
7. Специальность до призыва учащихся

3



8. Место рождения и постоянного жительства. Домашний адрес, фамилия, имя и отчество жены или родителей

9. Группа крови по Янскому


Примечание. Общие сведения записываются в штабе части. Сведения о групповой принадлежности крови вносятся санитарной частью.

4

II. Прохождение службы

| Часть, подразделение, занимаемая должность и звание | Месяц и число | Год и № приказа |
|---|---|---|
| 2 зап. полк 3 б-н 1 рота связи | 8/12 | 1943 |
| Присягу принял | 9.1. | 1944 |
| 6 отд. бат. [illegible] связи мл. сержант | 12.7. | 1944 |


# Салихов Шәфыйк абыйның үз кулы белән язылган автобиографиясе



1


Автобиография.

Салихов Шафик Салих улы
1926 елның 6 декабрендә туганмын
Арча районы Чомә-Елга авылында
1941 елда Сикертән җидееллык
мәктәбен тәмамлагач, колхозда
кырчылык бригадиры булып эшли
башладым. Шул ук елны Арча
педагогия училищесына укырга
кердем. 1943 елның ноябрендә
Арча хәрби комиссариаты тара-
фыннан армия чакырылдым
Арча райвоенкоматы Кукмара
военкоматы карамагына җибәрде
Кукмарадан Мәскәүгә озаттылар.
Аннан Мәскәүдән ерак түгел
Лосино-Островский разъездыннан
гына урман эчендә урнашкан
хәрби частька озаттылар.



2.

Аннан Мәскәүдән 30 км ераклыкта
урнашкан Пушкино шәһәренә күчер-
деләр. Анда элемтәчеләр курсында
механик-телефонист һөнәре би-
реп, сержант погоны тагып,
фронтка озаттылар. 3 нче Бело-
руссия фронтында 6 нчы аерым
элемтәчеләр батальонында отде-
ление командиры сыйфатында
башта үземә беркетелгән 14 сол-
дат белән батальон штабын сак-
ладык, аннан мине штаб элем-
тәчесе итеп күчерделәр, беркадәр
вакыт батальон командирының
адъютанты булып хезмәт иттем.
Без фронтка килгәндә штаб
Даугавпилс (Литва) шәһәре тирә-
сендә иде. Безнең часть Резекнә,
Шауляй шәһәрләрен азат итүдә



катнашты, Неман елгасы аша
кичеп Тильзит шәһәрен азат ит
Кингсберг юнәлешендә хәрәкәт ит
тек. Гади элемтәче сыйфатын
аркага катушка асып, алдагы х
рәкәт итүчеләр белән элемтә ур
наштыру иде минем бурыч.
Кингсбергка 30 км чамасы кал
бер тимерюл станциясе өчен бар
сугышта контузия алдым һәм
яраландым. Яра авыр булмаса
контузия көчле иде. Мине санча
кә озатканнар. 1945 елның 11 а
релендә Кингсберг алынды. Ки
сбергны алу белән 3 нче Белору
сия фронты бетерелде. Безнең
часть Кенигшика озатылды,
Мине дә (терелеп җитмәгән бу
сам да) үзләре белән алып кит

# Салихов Шәфыйк абыйның үз кулы белән язылган автобиографиясе

4.

ләр. Сугыш бетkәнне Байкал буенда-
гы Слюдянка шәһәрендә идетте.
Хәлем әйбәт булмагач, мине Ир-
кутскийга госпитальгә салдылар.
Госпитальдән 1946 елның маенда
армиядә хезмәт итәргә яраксыз
дип, инвалидность биреп кайта-
рып җибәрделәр.

1946 елның җәендә әти-әни,
туганнарым янында сәламәтле-
гем яхшырды. Арча педучилище-
сына III курска укырга бардым,
1947 елда тәмамлап, укытучы
булып эшли башладым. 1947-48
уку елында Курса Почмак баш-
лангыч мәктәбендә, 1948-1951 уку ел-
ларында Иске Масра башлангыч
мәктәбендә укыттым. Заочно
пединститутның тарих факуль-


5

тетын тәмамладым. 1951-56 уку-
елларында Сикертән мәктәбендә
тарих укыттым. 1956 елда Чүри-
ле КПСС райкомы Курса Почмак
мәктәбенә мәктәп директоры,
Фрунзе исемендәге колхозга парт-
оешма секретаре итеп җибәрде
1979 елга кадәр мәктәп дирек-
торы, 1988 елга кадәр тарих
һәм рус теле укыттым. 1986 ел-
дан пенсиядә. 11 ел колхозда
партоешма секретаре вазыйфа-
сын башкардым.

1988 елдан Казан шәһәрендә
яшим. Ватан сугышы инвали-
ды II группа, Ватан сугышы
бетүенең 55 еллыгына 3 бүлмә-
ле квартира (80м²) һәм җиңел
машина бүләк иттеләр.

хатыным Шәйхиева Фәузия.
1951 елда өйләнештек. 2 кызы-
быз, Фирдәүсә һәм Чулпан,
1 улыбыз, Нияз, бар.

Инв ВОВ II гр. „Закон о вете-
ранах ст. 14,
категория связист телефон-
ной связи, связист штаба
педаг. стаж 41, общий
стаж 47 ел (фронтовой перер



Исправление см. стр. 23

ВОЕННЫЙ БИЛЕТ

НЦ № 2141629

Фамилия Салихов

Имя Шафик Салихович

Отчество ~~Галимович~~

Число, месяц и год рождения 10 авг. 1926 г.

Личная подпись владельца Салих

Выдан Арским районным военным комиссариатом Татарской области (республики)

2 декабря 1963 г.

Место для фотокарточки

ВОЕННЫЙ КОМИССАР

М. П.

(звание, подпись)

НЦ № 2141629

1

I. Общие сведения

1. Место рождения Тат АССР Арский р-он д. Чура-Елга
2. Национальность татарин
3. Партийность (с какого года) член КПСС с 1954.
4. Состоит ли в ВЛКСМ (с какого года) не сост.
5. Образование Окончил Казанский пед институт в 1959.
6. Основная гражданская специальность учитель
7. Семейное положение жена Шайхиева Фаузие Динмухаметовна



Ленинский РОСО

(учреждение, выдавшее удостоверение)

г. Казань

УДОСТОВЕРЕНИЕ СЕРИЯ Р № 282922

Фамилия Салихов

Имя Шафик

Отчество Салихович

Личная подпись Салих

Предъявитель удостоверения является инвалидом второй группы и имеет право на льготы и преимущества, установленные действующим законодательством для инвалидов Отечественной войны.

УДОСТОВЕРЕНИЕ ДЕЙСТВИТЕЛЬНО НА ВСЕЙ ТЕРРИТОРИИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Дата выдачи 4 февраля 1994 г.

(подпись руководителя учреждения)

М. П.

МТ Гознака. 1992


БЕЛЕМ ИЛЕНӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!
PICKWICK
00 1 1

# *Бикбаев Госман Бикбай улы*




Бикбаев Госман Бикбай улы 1921 елда Арча районының Югары Курса авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 6 айлык вакытында әтисе үлеп китә. Тормышларыны бөтен авырлыгы 12 яшьлек абыйсы һәм әнисе җилкәсенә кала. Әнисе һәм абыйсыны тырышлыгы белән Госман абый үз авылларында 7 еллык белем ала.
Госман абый кечкенәдән укытучы булырга хыяллана. Аның хыялы тормышка аша. 1935-36 уку елында ул 1 курс студенты булу бәхетенә ирешә. 1938 елда укуын яхшы билгеләренә генә тәмамлый.
Шуннан соң аны Балтач районының Шубан авылына укытучы һәм мәктәп мөдире итеп эшкә җибәрәләр.


# *Бикбаев Госман Бикбай улы*



Алар мәктәпкә яшь белгечләр – 2 егет һәм 1 кыз тату гына эшлиләр. Ләкин Госман абыйга озак эшләргә туры килми. Аны һәм хзе белән бергә эшләгән егетне хәрби хезмәткә алалар. “Безне авыл яшьләре бик хуп күргәннәр иде. Авылда яшьләр белән аралашып, дус яшәдек. Шуңа күрә яшьләр-кызлар хәрби хезмәткә киткәндә военкоматка кадәр зурлап озата бардылар. Армиядә хезмәт иткәндә хат язып тордылар. Хезмәтне тутыргач кабат Шубанга кайтырга чакырып хат язалар иде”, дип сагынып искә ала ул елларны Госман абый. Хәрби хезмәтне Воронеж шәһәрендә башлап җибәрә Госман абый. 1-2 айдан соң Тамбов шәһәрендә урнашкан комсостав әзерли торган мәктәпкә укырга җибәрәләр.

# Бикбаев Госман абыйның үз кулы белән язган автобиографиясе





# Краснов Александр Фёдорович



1941 елда туа. 1943 елда сугышка алына, взвод командиры булып хезмәт итә. Җиңү көнен лейтенант дәрәҗәсендә каршылый. Күп санлы Ватан бүләкләренә лаек була.

Серия Т
№ 00888

Краснов
(фамилия)
Александр
(имя)
Федорович
(отчество)
и/н Б-810694



(личная подпись владельца билета)

М. П.

Военный билет выдан
„31“ октября 1948 г.
Аркинский Тат. АССР
(наименование военного комиссариата)
Аркин. Райвоенком
(должность, звание, подпись)
подполк. Потапов

## I. ВОЕННО-УЧЕТНЫЕ ДАННЫЕ

Серия Т

1. Род войск (служба) Автомобильные
ВУС № 62
2. Воинское звание лейт.
Приказ 46 арм.
3. Запас 4 разряда ___ разряда
3 разряда
4. Должность Командир взвода
5. Должен состоять на учете по 31 декабря 1964 года

---

Лейтенанту запаса
КРАСНОВУ АЛЕКСАНДРУ ФЕДОРОВИЧУ

Уважаемый АЛЕКСАНДР ФЕДОРОВИЧ!

Командование и политический отдел Военного Комиссариата ТАССР поздравляют Вас с 45-й годовщиной Советской Армии и Военно-Морского Флота.

Находясь на службе в рядах славных Советских Вооруженных Сил, Вы много сил и энергии отдали на благо нашей Родины, на дело укрепления обороноспособности страны.

Желаем Ва[...] хорошего здор[...] успехов в об[...]

Военный ко[...] полковни[...]

Начальник по[...] полковник

20 февраля






# Әүхәдиев Фәизи Диннулла улы



Әүхадиев Фәйзи Диннулла улы 1911 елның октябрендә туган. Яшьли ятим калып,балалар йортында тәрбияләнә. Бик кечкенәдән анда укытучы булу теләге туа.И элек рабфакны тәмамлый. Аннан соң Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә Ләкин институтны тәмамлый алмый, аны Ерак Көнчыгышка җибәрәләр. Аннан кайткач авылда балалар укыта башлый. 1941 елда Фәйзи абый үз теләге белән сугышка китә. Сталинград өчен барган сугышларда авыр яраланып госпитальгә эләгә. Госпитальдән чыккач , 61 отделениед элемтәче булып хезмәт итә. Фронтта 1944 елда коммунистлар партиясе сафларына керә.




Хезмәт ветераннары –Әүхәдиев
Фәйзи абый
һәм Фәхретдинова Ания апа
Курса Почмак авыл сәхнәсендә
чыгыш ясыйлар.
Фәхретдинова Ания апа да гоме
буе укытучы булып эшли.
Укытучылык эшен сугыш
елларында ук башлап җибәрә.

1941 - 19

# *Салихов Шәфыйкъ Салих улы*

Пушкино шәһәренә күчерәләр. Анда элемтәчеләр курсында механик – телефонист һөнәре биреп, сержант погоны тагып, фронтка озаталар. Өченче Белоруссия фронтында 6 нчы аерым элемтәчеләр батальонында отделение командиры сыйфатында үзенә беркетелгән 14 солдат белән батальон штабын саклый. Аннан Шәфыйкъ абыйны штаб элемтәчесе итеп күчерәләр. Берникадәр вакыт батальон командирының адьютанты булып та хезмәт итә.

Аларның штабы Даугаупилс (Литва) шәһәре тирәсендә урнашкан була. Алар Резекнэ, Шауляй шәһәрләрен азат итүдә катнашалар. Неман елгасы аша кичеп Тильзит шәһәрен азат итәләр. Шуннан соң Кинигсберг юнәлешендә хәрәкәт итәләр. Бу вакытта Шәфыйкъ абыйның бурычы – гади элемтәче сыйфатында, аркасына катушка асып, алдынгы хәрәкәт итүчеләр белән элемтә урнаштыру була.

# Салихов Шәфыйкъ Салих улы

Шәфыйкъ абый, Кинигсбергка 30 км чамасы калгач, бер тимер юл станциясе өчен барган сугышка контузия ала һәм яралана. Ярасы авыр булмаса да контузия көчле була. Шуңа күрә аны санчастька җибәрәләр.
Резекнэ, Шауляй, Тильзит, Кинигсберг шәһәрләрен азат итүдә катнаша.
1945 елның 11 апрелендә Кенигсберг шәһәре алына.Кенигсберг алыну белән 3 нче Белоруссия фронты бетерелә. Шәфыйкъ абыйларның частьларын Көнчыгышка озаталар. Терелеп бетмәс дә Шәфыйкъ абыйны да үзләре белән алып китәләр.Сугыш беткәнче Байкал буендагы Слюданка шәһәрендә хезмәт итә. Хәл әйбәт булмагач,аны Иркутск шәһәренә госпитальгә салалар.1946 елның маенда армиядә хезмәт итәргә яраксыз дип , инвалидностж бирепгоспитальдән  кайтарып җибәрәләр.

# *Салихов Шәфыйкъ Салих улы*

1946 елның көзенән Арча педучилищесында укуын дәвам итә. 1947 елда укуын тәмамлый һәм укытучы булып эшли башлый. 1947 – 48 уку елында Курса Почмак башлангыч мәктәбендә укыта. Читтән торып педагогия институтының тарих факультетын тәмамлый. 1951 – 55 уку елларында Сикертән мәктәбендә тарих укыта.

1956 елда Чүриле КПСС райкомы Шәфыйкъ абыйны Курса Почмак мәктәбенә директор итеп җибәрә. Мәктәп директоры буларак, Шәфыйкъ абый бик күп әә башкара. Мәктәптә белемле, тырыш коллектив туплана. Курса Почмак мәктәбе күп еллар мәгариф министрлыгының база мәктәбе булып тора. Мәктәпнең материаль – техник базасын ныгыту буенча планлы эш алып барыла. Мәктәп бинасына капиталь ремонт үткәрелә, кабинетлар заманча техник чаралар белән баетыла. Мәктәп янәшәсендә ике интернат бинасы, ашханә төзелә.

# *Салихов Шәфыйкъ Салих улы*

Шәфыйкъ абый 1979 елга кадәр директор булып эшли. Шуннан соң пенсиягә чыкканчы шул ук мәктәптә тарих һәм рус теле укыта. Бер үк вакытта 11 ел дәвамында Фрунзе исемендәге колхозда партоешма секретаре вазифасын да башкара.

1988 елдан Казан шәһәрендә яши, Икенче группа Ватан сугышы инвалиды буларак һәм Бөек җиңүнең 55 еллыгы уңаеннан Казан шәһәрендә 3 бүлмәле квартира һәм җиңел машина белән бүләкләнә. Җәй көннәрен Курса Почмак авылындагы йортына кайтып саф һавада үткәрә

1951 елда авылдашы Шәйхиева Фәүзия апа белән тормыш коралар. 2 кыз һәм 1 ул үстерәләр.

# Бикбаев Госман Бикбай улы

Госман абый анда да узенең укырга сәләтле булуын күрсәтә. Имтиханнарны яхшы билгеләренә генә тапшырып бара. Укуны тәмамлаганнан соң аларга “Средний комсостав по политчасти” дигән исем бирәләр һәм хәрби частька озаталар. Госман абый намус белән хәрби хезмәтен дәвам итә. Хезмәт срогымны тутыргач, туган ягыма кайтам, яраткан укытучы эшемне дәвам итәм дип хыялланып яши.

Ләкин шул вакытта Фин сугышы башлана. Махсус хәрби хезмәтне бетергән солдатларны фронтка җибәрәләр. Алар сайлап алынган яшь солдатларны сугыш техникасы белән эш итәргә өйрәтәләр, аларга башлангыч хәрби белем бирәләр.

Шуннан соң  Госман абый Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка алына. Сугыш чорында төрле операөияләрдә катнашырга туры килә Госман абыйга. Шул вакытларда да кешеләргә булган яхшы мөнәсәбәтен, ышанычын югалтмый ул.

# Бикбаев Госман Бикбай улы

“Сугышта минем белән бик ягымлы, үзен-үзе аямаучы, соңгы канын да кызганмаучы төрле яшьтәге украиннар, белоруслар, грузиннар бар иде. Сугыш беткәннән соң да күбесе белән хат алыштык” , дип яза ул. Смоленск шәһәре өчен барган сугышта доәман самолеты бомбага тотканда каты яралана һәм контузия ала. Дәвалану өчен аны Саратов шәһәрендәге госпитальгә җибәрәләр. Анда 4 ай дәвалана. Бары тик  1945 елның ноябрендә генә, барысы 7 ел хезмәт итеп, туган якларына кайта ветеран Госман абый. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен 14 дәүләт бүләгенә лаек була. Шулар арасында “1 дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены”, “За боевые заслуги” медале, “Маршал Жуков” медале да бар.

Госман абый тыныч тормышта үзенең  яраткан эшен дәвам итә. Югары Масра, Курса Почмак мәктәпләрендә балаларга белем бирә. Эш дәверендә күп санлы Мактаулар, грамоталарга, медальләргә лаек була.

# *Әүхәдиев Фәйзи Диннулла улы*

Фәйзи абый Польша ,Чехословакияне азат итүдә катнаша. Германиягә кадәр барып җитә.

Коммунист Фәйзи әүхадиев Смоленск,Выборг крепостьларын алганда, көнья
көнбатыш Оппельн немеө группировкасын тар-мар иткәндә ,фашистларның
ныклы оборона пункты булган Нейссы шәһәрен алганда батырлыклар күрсәт
Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Фәйзи Диннулович “Кызыл Байрак ордены” белән бүләкләнә.

Сугыштан соң Фәйзи абый укытучылык эшен дәвам итә.1948 елдан алып 195
елга кадәр Иске Масра һәм Курса Почмак җидееллык мәктәпләрендә директ
булып эшли.

Лаеклы ялга чыккач та Фәйзи абый балалар ,өлкәннәр арасында тәрбия эшен алып баруын ташламый. Ул мәктәптә балалар янында еш була. Гадилеге , эчкерсезлеге , тәрбиялелеге өчен аны һәркем дә ихтирам итә. Фәйзи абый үзешчән сәнгатьтә дә актив катнаша. Ул матур итеп скрипкада да һәм башка уен коралында да уйный.

Курса Почмак авылында тормыш иптәше Хәдичә апа белән матур гына гомер итәләр.Ялгызы калгач ул кызлары Руя апа тәрбясендә Казан шәһәрендә яши.

# *Бөек ватан сугышында һәлак булган укытучылар*

# *Бөек ватан сугышында һәлак булган укытучылар*

# *Бөек ватан сугышында һәлак булган укытучылар*

# *Бөек ватан сугышында һәлак булган укытучылар*